**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 25 декабрендәге 5341 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 22 октябрендәге 2782 номерлы «Вахитов районының Спартак урамындагы җир кишәрлекләренең бер өлешенә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан электр челтәрләренең – «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте филиалының Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 22 октябрендәге 2782 номерлы «Вахитов районының Спартак урамындагы җир кишәрлекләренең бер өлешенә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакындагы гаризасы нигезендә, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясына, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлегенә таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 22 октябрендәге 2782 номерлы «Вахитов районының Спартак урамындагы җир кишәрлекләренең бер өлешенә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. 7.1 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**